№1, сентябрь, 2013 ел



# Бөреләр

Балалар һәм үсмерләр газетасы

## Бу санда:

**Мәктәп тормышы**
**Укучылар уңышлары**
**Илдә ниләр бар икән?**
**Туган телем**
**Белемнәрне тикшерик**
**Иҗат**
**Ял минуты**




## 1 сентябрь - “Белем бәйрәме”

“Исәнме мәктәп!”

Алтын көздә һәр ел саен
Без киләбез мәктәпкә.
Яхшы укырга икәнен
Без беләбез әлбәттә.

Бәйрәмгә әзерлек эшләрен алдан ук башлап җибәрдек. 1 нче сыйныфка килүче укучылар тырышып шигырьләр, өлкән сыйныфтагы укучылар җырлар, биюләр өйрәнде. Менә дулкынланып көткән көн килеп тә җитте. Һәр бала чәчәк бәйләмнәре тотып, мәктәпкә ашыкты. Бәйрәмгә бик күп кунаклар килгән иде. Алар укытучыларыбызны, безне бәйрәмебез белән котладылар. Бәйрәм бию-җырләр белән үрелеп барды. Кыскасы, һәркемнең йөзендә елмаю чаткылары балкыды. Хәерле сәгатьтә хөрмәтле дуслар!






1. Укучылар өчен мәктәптә чаңгы спорты, баскетбол, шахмат, "Оста куллар", "Яшь программист” һ.б. түгәрәкләре эшли. Бу түгәрәкләргә укучылар кызыксынып йөриләр. Кызыктыңмы? Әйдә, кыюсызланып торма! Без сине үзебездә көтәбез!
- Син җырлыйсың? Бик әйбәт.
- Син спортны яратасың? Тагы да яхшырак!
- Рәсемгә дә осталыгың бар? Менә бит!

Димәк, син безнең кеше. Тизрәк әти-әниең белән киңәшләш тә, туры безгә юл тот! Без сине көтәбез. Әгәр кызыксынсаң, сезне тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Марина Юрий кызы Айканова көтеп кала.

2. “Кросс – 2013” ярышында мәктәбебездән 10 кеше катнашты. Шулардан 4 кеше призлы урынга лаек булдылар. Егетләр арасында 3 км дистанциядә Хөснетдинов Фәнис 3нче урынга, “Иң яшь катнашучы” номинациясендә Демин Евгений бүләккә лаек булдылар.Кызлар арасында 2 км дистанциядә Васюткина Елизавета“Иң яшь катнашучы” номинациясендә бүләкләнде. Җиңүчеләрне котлыйбыз. Алдагы ярышларда уңышлар телибез.

3. 13.10.2013- Мәктәбебездә сугыш ветераннары белән очрашу үткәрелде. Укучылар кунакларга үзләренең чыгышларын күрсәтеләр һәм ветераннарга истәлекле бүләкләрен тапшырдылар.Тыл һәм сугыш ветераннарына7-8 сыйныф укучылар шефлыкка бардылар.

# Укучылар уңышлары

Үзеңнең буш вакытыңны файдалы һәм мавыктыргыч итеп үткәрү өчен тормышта кызыклы шөгелләр бихисап. Мәсәлән, берәүләр сурәт төшерергә яратса, икенчеләре илһамланып шигырь яза, кемдер элекке акчалар, сувенерлар яисә маркалар җыя һ.б.



## Оста куллыларга эш карышмый

Ә менә мәктәбебезнең 8 Б сыйныф укучысы Булат Нафиков исә шөгыльнең тагын да үзенчәлеклесен һәм катлаулырагын тапкан. Ул гипстан, агачтан, шырпыдан һәм торбачыклап төреп, төрле әйберләр ясарга өйрәнгән.

Булатның мондый гаҗәеп, киңкырлы сәләтен мәктәбебезнең технология укытучысы Фәнил Рәфис улы да хуплый.

Булат искиткеч сабырлык һәм тырышлык таләп иткән эш белән биш еллап шөгелләнә икән. Шул вакыт эчендә аның оста куллары белән иҗат ителгән әйберләр хәтсез җыелган. Ул модульле оригами ысулы белән кәгәзьдән “ТУ-154” самолеты, паровоз, шырпы бәртекләреннән заманча янгын сүндерү машинасының макетларын һ.б. ясаган.

Гипстан катырып эшләнгән дирижабль, пароход, паровоз, КамАЗ, «Джип» автомобильләренең макетлары һәм башка күпсанлы әйберләр аның искиткеч бай коллекциясен тагын да тулыландыра һәм матурлый.

- Нинди генә эшкә алынсаң да, аның нәтиҗәсен күреп куанганчы бер-ике ай чамасы вакыт уза. Әмма илһамланып, ләззәтләнеп иҗат иткән чакта вакытның үткәне сизелми дә ул, -дип уртаклаша Булат.

Киләчәктә, әлбәттә, бу шөгелем белән җитди мавыгырга ниятлим, - дип елмая ул.

## Җырла, Илшат, сокланмаган кеше калмасын

Кечкенә инеш яки чишмәсе булган урман-кырлар киңлегендә кошлар моңы тынып тормый. Анда бер кош икенчесен алыштырып җырын суза, барысы бергә кушылсалар, илаһи ансамбль барлыкка килә. Би-и-ик ерактан, борынгыдан килә җыр-моң тарихы. Ә Илшат кебек җырчы егетләр булганда, ул әле бик тә дәвамлы булыр.

Мәктәбебезнең 5Гсыйныф укучысы Илшат Назмиев та күренкле җырчылардан калышмый. Җиде яшьтән җырлый инде ул. Табигатьтә берсеннән-берсе моң откан кошлар кебек, Илшат та үзенең яраткан җырчы Рөстәм Асаевның җырлавын тыңлап үскән.

– Җырларга бигрәк яратам, җырчы буласым килә, – ди Илшат. – Өч яшьлек туганыма да җырлыйм, әтием-әниемә дә. Балалар бакчасына йөргәндә үк җырлый башлаган идем. Беренче итеп композитор Альбина Имаеваның “Чын дустым” җырын җырлаган идем. Мәктәптә безне музыка укытучысы Венера Вагыйз кызы дөрес җырларга өйрәтә. Синтезаторда уйныйм, ноталар өйрәнәм. “Ике йолдыз” шәһәр конкурсында катнашып, икенче урын алдым, республика конкурсларына барганым юк әле, – дип тыйнак кына елмайган егеткә сокланып туймаслык.




Менә бөтен матур сыйфатларны да җыйган бит үзенә: җырчы да, яхшы укый да, тыйнак та... Үзе бүгенге эстрада белән тынышып бара, Радик Юлъякшин башкаруында “Ашкынма гомер” дигән җырны тыңларга ярата икән. Хыялы – инглиз телендә дә җырларга өйрәнү һәм зур конкурсларда катнашу. Аның өчен музыка мәктәбенә әлегергә кирәк, былтыр соңлап барганнар, быел бәхетен сынап карамакчы әле. Ә беләсезме, Илшатның җырчы һәм... хирург буласы килә бит. Ә нигә булмаска?! Мондый моңлы җан табиб булса, ул кешеләрне аеруча тиз дәвалар иде, күңеле бигрәкләр матур шул аның, күзләр тимәсен...

## *Илдә нилә бар икән?*



## *Күз ачып йомганчы ...Казанда!*

Ике тугандаш кала арасын тагын да ныграк якынайтып махсус программа буенча самолет оча башлаячак димәкчебез. Шартлары да бик уңайлы булмакчы: самолетка билетны ташламалы хак белән сатачаклар. Билет хакының яртысын пассажир үзе түләсә, калган яртысын түләүне дәүләт үз өстенә алачак: 25% - федераль, калган 25 % төбәк бюджетлары күтәрәчәк. Программаны тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан 300 млн. сумм акча бүленәчәк. Әйткәндәй, Казан каласыннан башка Идел буеның Түбән Новгород, Пермь, Киров кебек калаларына да шундый ук шартларда очу мөмкинлеге тудырылачак.

## *Туган телем*

### *Туган телләр язмышы*

Белгечләр киләсе йөзьеллыкта барлык телләрнең 95% ы яшәүдән туктар дип фараз итә. Мәсәлән, бер ел эчендә 10 тел юкка чыга дигән фикер бар.
Җир йөзендә бүгенге көндә 6000 тел бар дип исәпләнә. Шулардан иң күп санлы кешеләр тарафыннан кулланыла торганы — кытай теле, бу телдә 1,2 млрд. кеше сөйләшә, инглиз телендә — 478 млн.; хинди телендә — 437 млн.; испанда — 392 млн.; рус телендә — 284 млн.; гарәптә — 225 млн.; португалда — 184 млн.; француз телендә 125 млн. кеше сөйләшә.
Тел ягыннан аеруча чуар булган төбәкләрдә телләрнең юкка чыгуы бигрәк тә көчле. Африкада биш йөздән кимрәк кеше сөйләшә торган 200 тел барлыгы билгеле, АКШ һәм Канадада индеецларның 200 теле юкка чыгу алдында тора дип саныйлар. Көньяк-Көнчыгыш Азиядә 600-700 тел бар, шуларның кырыгы дәүләт ярдәменә мохтаҗ. Европа илләрендә 123 телдән тугызы юкка чыккан, егерме алтысы югалу алдында тора, тагын 38 телгә шундый ук куркыныч яный.

# Белемнәрне тикшерик



**5 нче класста өйрәнгәннәрне гомумиләштереп кабатлау**.

1. Иренләшкән сузыкларны күрсәтегез.
   А) [у ], [ү ], [ө ], [о ], [о ]
   Б) [ә], [а ], [ы ], [ы ], [э ], [э ].
   В) [у ], [а ], [ү ], [ә ], [ө ], [ы ], [о ].

2. Басымы өченче иҗеккә төшкән сүзләрне күрсәтегез.
   А) бара, барабыз, алсын, кызыл, татарча, карармын.
   Б) әнә, яшә, барма, килмә, һаман, ләкин, , әмма.
   В) алганнар, күрешкән, ышангандыр, ишеткәнсең.

3. ь хәрефе кайчан аеру билгесе булып килә ?
   А) рус теленнән кергән сүзләрдә;
   Б) алдагы иҗекләрнең нечкәлеген беолдергәндә;
   В) кушма сүзләрдә тамыр я, ю, е хәрефләренә башланса.

4.. Сингармонизм законына буйсынган сүзләрне күрсәтегез.
   А) бодай, әни, ата-ана, гөлҗимеш, үзсүзле;
   Б) Миңсылу, бераздан, дөнья, төнозын, һәрвакыт, ир-ат.

5. Сингармонизм законы нәрсәгә карап билгеләнә?
   А) язылышка карап;
   Б) әйтелешкә карап;
   В) әйтелеш һәм язылышка карап.

6. Лексика нәрсәне өйрәнә ?
   А) аваларны һәм хәрефләрне;
   Б) сүзләрнең ясалышын һәм төзелешен;
   В) сүзлек байлыгын;

# Иҗат

## "Яшел яфрак"

Алтын төскә буяп бар дөньяны,
Килеп җитте инде салкын көз.
Мин йөримен, ялгыз, урман буенда,
Йөрәгемдә никтер күңелсез.
Күңелем тулы төрле хатирәләр,
Төрле кешеләр аны билэп алганнар.
Кайсыберләр мине иркәләгән,
Ә кайберләре яра салганнар.
Төрле хыялларда йөзеп йөргәндә,
Килеп кунды кулыма бер яфрак.
Салкын җилләр аны агачыннан өзеп,
Алып киткәннәрдер инде бик ерак.

Шайнурова Альбина, 9 А укучысы

## Безнең гаилә

Безнең гаилә зур. Гаиләдә алты кеше. Минем әбием,әнием, әтием,апам бар. Алар барысы да эштә, ә мин укуда. Кич белән барыбыз бергә җыелабыз. Әбием бәйли, әнием чигү чигә, әтием телевизор карый, апам миңа дәрес хәзерләшергә булыша. Без дус яшибез.

Акберова Алина, 2 Г укучысы

# Ял минуты

"2 сурәт - 1 сүз"

Уен кагыйдәләре: ике сурәтнең һәрберсендә яшерелгән сүзне табырга һәм шулардан җавапны төзергә. Беренче сурәттәге сүзнең азаккы хәрефе икенче сүзнең беренче хәрефе белән туры килергә мөмкин. №1. 7 хәреф №2. 6 хәреф







10 аерманы тап.

Безнең адрес: Нефтекама шәһәре, Социалистик урамы, 45 Б санлы йорт.
Белешмәләр өчен телефон: 8(927) 322-53-73.